**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 4 сентябрендәге 3781 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан җир кишәрлегенә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 118 кв.м;

- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:100419:54;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;

- урнаштыру максаты: электр белән тәэмин итүне (технологик тоташтыруны) оештыру өчен;

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүчеләр: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында 2023 елның 28 февралендәге 2023/КЭС/Т109 номерлы килешү.

2. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә раслана дип билгеләргә.

4. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның

гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.http://www.dockskzn.ruhttp://www.pravo.tatarstan.ru

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.http://www.dockskzn.ru

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең хокук иясе белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, файдалану, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 сентябрендәге
3781 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:1000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| (яшел сызык) | билгеләнә торган сервитут чиге |
| (соры сызык) | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |

| | |
|---|---|
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:100419 | кадастр кварталы |
| 16:50:100419:54 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең |